Чыганак: **Таҗи Гыйззәт: истәлекләр, мәкаләләр / авт.-төз. К. Гыйззәтов.- Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.- 151 б.**

Җәүдәт Фәйзи

# ТАТАР МУЗЫКАЛЬ ДРАМАСЫНА ӨЛЕШ КЕРТҮЧЕ[1]

...Әгәр дә драматург Мирхәйдәр Фәйзи үзенең «Галиябану» әсәре белән музыка сәнгатен беренче буларак сәхнәгә күтәреп чыкса, Таҗи Гыйззәт чын мәгънәсендә музыкаль драматургия тудырды һәм үзенең «Наемщик», «Бишбүләк» кебек тирән эчтәлекле, тормышның катлаулы бәрелешләрен дөрес чагылдырган музыкаль драмалары белән татар совет операсын тудыруга әзерлек алып барды, аңар нигез салды.

Т.Гыйззәтнең музыкаль драмалары татар совет композиторларының үсүенә, профессиональ югарылыкка күтәрелүенә сәбәп булып килделәр. Аның яхшы йогынтысында бигрәк тә халык композиторы Салих Сәйдәшев булды.

Әгәр дә күптән түгел генә арабыздан киткән сөекле композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең искиткеч музыкаларын без тыңлап сокланабыз икән, аларның тууына Таҗи Гыйззәт сәбәп булды. С.Сәйдәшевнең иң яхшы музыкалары Т.Гыйззәтнең «Наемщик» һәм «Бишбүләк» драмалары аркасында тудылар.

Шуның өчен дә безнең киң катлау тамашачыларыбыз киләчәктә, «Наемщик», «Бишбүләк» дигән исемнәрне ишетү белән, Т.Гыйззәт һәм С.Сәйдәшевне зур хөрмәт белән искә алачаклар.

Таҗи Гыйззәт татар театры сәнгате өчен беренче буларак яңа жанр – музыкаль комедия жанрын барлыкка китерде. Аның «Башмагым» комедиясе Татарстанда гына түгел, Ватаныбызның күп кенә почмакларында да билгеле. Ул әсәр 1950 елдан бирле Мәскәү радиосы аша рус телендә һәм чит илләр өчен радио тапшырулары программасында булып, уналты телдә яңгырый. Болардан тыш танылган драматургның «Башмагым» комедиясе үзбәк, украин, кыргыз һәм бурят-монгол телләренә тәрҗемә ителеп, Ташкент, Киев, Харьков, Свердловск, Улан-Удэ һәм башка шәһәрләрдә сәхнәгә куелды, куела һәм куелырга әзерлек алып барыла.

Болар бар да Таҗи Гыйззәтнең татар совет музыка культурасын үстерүдә булган гаять зур хезмәте турында сөйлиләр.

Таҗи агадан аерылу – татар совет культурасының бөтен тармаклары өчен генә түгел, безнең советлар иленең гомуми культурасы өчен дә зур югалту.

Без, татар композиторлары, татар совет музыкасының якын дусты, аны чын йөрәктән ихтирам итүче, эшебездә зур ярдәм күрсәтүче Таҗи Гыйззәтне һәрвакытта зур ихтирам белән искә алачакбыз, чөнки аның ялкынлы иҗаты безнең музыкаларыбызда яңгыраячак.

*1955*

---

[1] Мәкалә Ж.Фәйзинең Т.Гыйззәтне күмү митингында сөйләгән текстыннан алынды. (*Авт.-төз. искәрмәсе.*)